ПРОЕКТ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2025 елның «__» маеннан № ____

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә җылылык белән тәэмин итү системасында авария хәлләре килеп чыкканда (барлыкка килү куркынычы булганда) кулланучыларның җылылык энергиясен куллану режимнарын авария хәлендә чикләү һәм җылылык энергиясен бирүне чикләү, туктату графиклары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 23 августындагы 185 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының «Җылыту чорына әзерлекне тәэмин итү кагыйдәләрен һәм җылыту чорына әзерлекне бәяләү уздыру тәртибен раслау турында» 2024 елның 13 ноябрендәге 2234 номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә җылылык белән тәэмин итү системасында авария хәлләре килеп чыкканда (барлыкка килү куркынычы булганда) кулланучыларның җылылык энергиясен куллану режимнарын авария хәлендә чикләү һәм җылылык энергиясен бирүне чикләү, туктату графиклары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 23 августындагы 185 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Керештә «Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының 2013 елның 12 мартындагы 103 номерлы боерыгы белән расланган җылыту чорына әзерлекне бәяләү кагыйдәләре» сүзләрен «Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының 2024 елның 13 ноябрендәге 2234 номерлы боерыгы белән расланган җылыту чорына әзерлекне тәэмин итү кагыйдәләре һәм җылыту чорына әзерлекне бәяләү уздыру тәртибе» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (инфраструктур үсеш буенча) йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Е.А. Тарнавский